ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**
08.06.2015

**БОЕРЫК**
№ 154

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә Иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябрендәге 856 санлы, 2013 елның 24 октябрендәге 793 санлы, 2014 елның 20 сентябрендәге 669 санлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып),
боерам:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакындагы» 2010 елның 24 декабрендәге 364 санлы боерыгы үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис — М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
боерыгы белән расланды
от 08.06.2015 № 154

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты
каршындагы Иҗтимагый совет турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы тарифлар буенча комитетының (алга таба - Дәүләт комитеты) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, өстәмә бәяләрне һәм башкаларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләти идарә итүне һәм Татарстан Республикасында бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, өстәмә бәяләрне һәм башкаларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм гамәлгә ашыру барышында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый оешмаларның һәм башка дәүләти булмаган коммерциясез оешмаларның хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтүләргә, аларның нәтиҗәлелегенә һәм куркынычсызлыгына хокукларын, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт контрольлек һәм күзәтчелек итү системасын камилләштерүне гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерүне башкаручы киңәшү органы булып тора, ул шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне башкара.

1.2. Иҗтимагый совет составы һәм саны Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый Совет турында Нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә)таяна.

1.4. Иҗтимагый совет тәкъдим рәвешендәге карарлар кабул итә ала.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычында башкара.

1.6. Иҗтимагый совет эшчәнлеге ирекле нигездә, ачыклык һәм партнерлык принципларына һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына нигезләнеп башкарыла.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген гражданлык җәмгыяте институтлары вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, гавами мәгълүмат чараларының үзара хезмәттәшлеге нигезендә башкара.

2. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, Татарстан Республикасы территориясендә бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, өстәмә бәяләрне һәм башкаларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм гамәлгә ашыру барышында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый оешмаларның һәм башка дәүләти булмаган коммерциясез оешмаларның хокукларын яклау;

Дәүләт комитеты эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру;

Дәүләт комитеты тарафыннан күрсәтелгән дәүләти хезмәтләрнең сыйфатына җәмәгатьчелек контролен көчәйтү, товарларга (эшкә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, өстәмә бәяләрне һәм башкаларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм һөнәрилек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый Совет бурычларына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы территориясендә товарларга (эшкә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, өстәмә бәяләрне һәм башкаларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Дәүләт комитеты эшчәнлеге өлкәсенә караган норматив хокукый актлар проектларына җәмәгатьчелек экспертизасы ясау;

законнарда каралган очракларда Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актларны алдан карап тикшерү;

Дәүләт комитеты карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә, шулай ук Россия Федерациясендә килеп туган икътисадый, социаль һәм сәяси хәлләр исәпкә алынып, үзгәрергә һәм тулыландырылырга мөмкин.

## 2. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет гражданнар, социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар тәкъдиме нигезендә рәис, рәис урынбасары, сәркатиб һәм Иҗтимагый совет әгъзалары составында төзелә. Иҗтимагый советның персональ составы Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә кимендә 5 кешедән һәм 30 кешедән артмаган составта төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре санынннан Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар вәкилләре керә ала. Шуның белән бергә аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне карап тикшерү өчен зарури булган тиешле белеме, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән бергә Иҗтимагый совет әгъзалары гомуми санының яртысын тәшкил иткән санда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар кертелә.

3.4. Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын биләгән затлар, Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык вазифаларын биләгән затлар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазифаларын биләгән затлар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык вазифаларын биләгән затлар, муниципаль вазыйфаи урын биләгән һәм муниципаль хезмәт вазифасын биләгән затлар, суд карары белән хокукка сәләтсез дип табылган затлар, кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителеше булган затлар, ике ил гражданлыгына ия затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар, шулай ук бу «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Иҗтимагый совет әгъзалары була алмаган башка затларга да кагыла.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан, әгәр алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән сайланалар. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын вазифадан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризасы буенча яисә Иҗтимагый советның барлык әгъзалары санының биштән бер өлеше тәкъдиме белән, шулай ук Дәүләт комитеты мөрәҗәгате буенча карала.

Әгәр карар өчен Иҗтимагый совет әгъзалары гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, карар кабул ителгән санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзалары вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның тарафыннан Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирелгәндә;

сәламәтлеге зәгыйфь булу сәбәпле, Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкинлеге булмаганда, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән үз теләге белән яисә башка сәбәпләр аркасында читләшкәндә;

суд тарафыннан аңа карата чыгарылган хөкем карары законлы көченә кергәндә;

үзенең законлы көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез яки хәбәрсез югалган дип таныганда;

этик нормаларны тупас бозганда– утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктатканда ;

чит ил дәүләте гражданлыгын (подданствосын) алганда;

Иҗтимагый совет утырышында системалы рәвештә (өчтән артык) нигезле

сәбәпләрсез катнашмаганда;

системалы рәвештә (икедән артык) Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне нигезле сәбәпләрсез үтәмәгәндә;

аны Россия Федерациясенең дәүләт вазифасына, Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык вазифасына, муниципаль вазыйфаи урынга һәм муниципаль хезмәт вазифасына билгеләгәндә.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы булудан туктау Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы нигезендә кабул ителгән Дәүләт комитеты рәисе карарына таянып яисә Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасарының тәкъдиме буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында каралган хәлләр ачыкланган очракта башкарыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге зәгыйфь булу аркасында эшчәнлекне башкара алмаганда, суд тарафыннан аңа карата чыгарылган хөкем карары законлы көченә кергәндә, Россия Федерациясе гражданлыгын туктатканда, әлеге мәгълүматларны Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Дәүләт комитеты рәисе карарына таянып, түбәндәге очракларда туктатылып тора:

Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләүне белдергәндә;

административ төстә сак астына алу рәвешендә административ җәза биргәндә;

дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат вазифасына кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазифага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәлгәндә, шулай ук Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Дәүләт комитеты инициативасы белән үткәрелгән барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ.б.), федераль закон нигезендә дәүләт серен, персональ мәгълүматлар һәм чикләнгән мәгълүматларны тәшкил иткән мәгълүматлардан файдалануга бәйле катнашу мөмкинлеге чикле булган чаралардан тыш, катнашырга;

Иҗтимагый советка инициатив тәртиптә аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати- аналитик материаллар әзерләргә һәм юнәлтергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерүдә катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

әлеге Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

Иҗтимагый совет тарафыннан куелган бурычларны хәл итү өчен төзелгән эксперт төркемнәр, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшчәнлегендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән Иҗтимагый совет утырышында расланган план һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшчәнлеген планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Дәүләт комитеты тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары өй айга кимендә бер мәртәбә үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнеп, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерелмичә кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 санлы карары белән расланган башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнеп, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерелмичә кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган норматив хокукый актларның Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнгән проектларына һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы юстиция министрлыгына теркәлү өчен юнәлтелә торган норматив хокукый актларга Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатында Дәүләт комитеты инициативасы буенча да үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе утырышларда катнашса, Иҗтимагый совет утырышлары вәкаләтле дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасының утырышта катнашу мөмкинлеге булмаганда, ул бу турыда Иҗтимагый совет рәисенә, аның урынбасарына яисә җаваплы сәркатибенә алдан хәбәр итеп, башка Иҗтимагый совет әгъзасына үз тавышын һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә, факсимиль

яисә электрон хат аша юнәлтә ала. Иҗтимагый совет әгъзаларының утырышта катнашкан санына башка Иҗтимагый совет әгъзаларына үз тавышларын ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да кушыла.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3. пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектлары (норматив хокукый актлар) Дәүләт комитеты тарафыннан Иҗтимагый советка юнәлтелгән көннән алып ун календарь көн дәвамында карала. Аларга Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатында тавыш бирү Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән башкарыла, сораштыру нәтиҗәләре Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда рәис урынбасары кул куйган беркетмәгә кертелә. Мондый тавыш бирү җибәрелгән һәм кабул ителгән хәбәрләрнең аутентиклыгын һәм аларның документаль рәвештә раслануын тәэмин итә алган почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яисә башка элемтә аша документлар әйләнеше юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү очрагында утырыш үткәрүгә кимендә җиде календарь көн кала Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителгән көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсен таләп иткән норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) юнәлтелә. Иҗтимагый совет әгъзалары зарури булганда Дәүләт комитетыннан каралучы норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат сораталар һәм алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышын Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый совет үз алдына куелган бурычлар, максатлар, вәкаләтләр нигезендә тәкъдим рәвешендәге карарлар  кабул итә һәм алар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән чыгарылма рәвешендә яисә Иҗтимагый совет карары белән башка ысул кулланып, кызыксынган затлар игътибарына җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт комитеты сайтының Иҗтимагый совет күрсәтмә битендә урнаштырыла.

5.8 Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аңа үзгәрешләр кертә һәм Иҗтимагый совет раславына куя;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый советның тәкъдим рәвешендәге карарларына, беркетмәләргә һәм Иҗтимагый советның башка документларына кул куя;

Иҗтимагый совет утырышын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

үз алдына куелган максат һәм бурычлар, Иҗтимагый совет эшчәнлеге

кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

Иҗтимагый совет исеменнән запросларга, тәкъдимнәргә, жавапларга, аңлатмаларга, мөрәҗәгатьләргә кул куя.

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен зарури булган башка вазифаларны башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә урынында булмаганда, аның вазифаларын башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслау өчен тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен зарури булган башка вазифаларны башкара.

5.10. Иҗтимагый совет сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый советны үткәрү урынын һәм вакытын, көн тәртибен хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә:

Иҗтимагый совет һәм Дәүләт комитетының үзара оештыру хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин ителешен башкара;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен төзи һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

Иҗтимагый Совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары мәсьәләләрне Иҗтимагый Совет утырышларында тыңлауга һәм тикшерүгә әзерләү өчен эш төркемнәренә, эксперт төркемнәренә яисә башка эш органнарына берләшергә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешенеп, материаллар әзерләүгә Иҗтимагый Совет составына кермәгән белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет тарафыннан каралган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр алу өчен Иҗтимагый Совет утырышларына башкарма органнар, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырыла ала. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган гавами мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнаша алалар.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелүче материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына Иҗтимагый совет утырышы билгеләнгән вакытка кимендә ун календарь көн кала, тапшырылырга тиеш. Материалларны күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки аның урынбасары белән килешенә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең техник һәм оештыру яктан тәэмин ителешен Дәүләт комитеты башкара.